елгасы белән кушылган җиргә кадәр уза, Бидәңге елгасы агымы буенча 4,3 км өскә таба Кошки-Новотимбаево, Олы Тархан һәм Бакырчы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үтәмеш авылыннан 500 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Бакырчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып Килнә елгасы агымы буенча 4,6 км өскә таба уза, аннары 750 м көньякка таба, яр буендагы агач-куак массивын һәм саклау валын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, «Киртәле – Кошки-Новотимбаево» – Чуаш Чурапаны автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,0 км, урман полосасы буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,1 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м Бидәңге елгасына кадәр уза, аннары бу елга агымы буенча 250 м аска таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

6) 23 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

## Тәтеш муниципаль районының «Льяшево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Льяшево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Льяшево авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Алабирде, Зур Әтрәч, Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Нармонка авыл җирлекләре белән чиктәш.

Льяшево авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Льяшево, Олы Шәмәк һәм Олы Тормы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Шәмәк авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Апас – Тәтеш» – Олы Шәмәк – Кече Шәмәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешләрне һәм текә ярны кисеп үтеп, 1,3 км Олы Шәмәк, Льяшево һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бисәр авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Льяшево авыл җирлеге чиге Олы Тормы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Льяшево, Олы Тормы һәм Алабирде авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алабирде авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,8 км, зиратның көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, аннары 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Үләмә елгасына кадәр бара, шуннан соң бу елга агымы буенча 1,1 км өскә таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Апас – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Льяшево авыл җирлеге чиге Алабирде авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Льяшево, Алабирде һәм Зур Әтрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Әтрәч авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, шуннан соң

бу инеш агымы буенча 1,9 км аска таба ул Шонга елгасына койган җиргә кадәр бара, бу елга агымы буенча 550 м аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнбатышка, чокырларны һәм Алабирде – Ямбакты автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,0 км көньяк-көнбатышка таба, Үләмә елгасын кисеп үтеп, 950 м төньяк-көнбатышка таба, 450 м көньяк-көнбатышка таба бара, урман полосасының төньяк чиге буйлап 1,2 км 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Льяшево авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Льяшево, Зур Әтрәч, Монастырский авыл җирлекләре һәм «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Монастырский авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, аннары 3 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 3 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 300 м төньяк-көнбатышка таба 3 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң 150 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м уза, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 3 нче, 4 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м бара, 4 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 850 м уза, шуннан соң 100 м төньякка таба урман массивының көнбатыш чиге буйлап бара, төньяк-көнчыгышка таба 148 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 148 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан

соң 250 м көньяк-көнчыгышка таба 148 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 148 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, 30 м көньяк-көнчыгышка таба урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 4 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, 2 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м төньяк-көнбатышка таба, 450 м көньяк-көнбатышка таба бара, 1 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м, 1 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 40 м бара, 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Льяшево авыл җирлеге чиге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып 10 м көньякка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньякка таба, 750 м көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 500 м аска таба буага кадәр бара, аннары буа буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң инеш агымы буенча 1,7 км аска таба бара, аннары көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Апас — Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,8 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Нармонка һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Льяшево авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Льяшево авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 500 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба чокыр буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң бу инеш агымы буенча 950 м аска таба уза, сынык сызык ясап, 1,7 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Үләмә елгасына кадәр бара, шуннан соң бу елга агымы

буенча 250 м өскә таба бара, аннары 4,0 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

7) 27 һәм 28 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
27 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының «Монастырский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Монастырский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Монастырский авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зур Әтрәч авыл җирлеге, Кама Тамагы һәм Спас муниципаль районнары белән чиктәш.

Монастырский авыл җирлеге чиге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Монастырский авыл җирлеге, «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ильинский авылыннан 3,5 км көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сусаклагычның текә уң ярын кисеп үтеп, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 850 м, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталы буйлап 450 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны берничә тапкыр кисеп

үтеп, 400 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м, 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 750 м бара, көнбатышка таба 139 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 20 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Тәтеш – Кама Тамагы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м, урман массивының көньяк чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярларны, урман полосасын, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,4 км Үләмә елгасына кадәр бара, аннары бу елга агымы буенча 650 м аска таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 4,7 км төньякка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 600 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Монастырский авыл җирлеге, «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зур Әтрәч һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монастырский авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монастырский авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Монастырский, Зур Әтрәч авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лаптевка авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кариле участок урманчылыгындагы 46 нчы, 47 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 900 м бара, 47 нче урман кварталы буйлап инешкә кадәр 50 м уза, шуннан соң бу инеш агымы буенча 650 м аска таба ул бүтән инешкә койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 550 м өскә таба бара, шуннан соң 750 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,1 км, көньяк-көнчыгышка таба 800 м уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, урман полосасы буйлап 400 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 900 м, «Тәтеш урманчы-

лыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 144 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, 100 м, көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м уза, аннары 950 м көньякка таба бу автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 20 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, 2 нче, 4 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монастырский авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Монастырский авыл җирлеге, Кама Тамагы һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Долгая Поляна авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 28 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Монастырский авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 28 нче (34 нче) тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
28 нче кушымта

## Тәтеш муниципаль районының «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын

(«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Нармонка авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Олы Шәмәк, Келәш, Льяшево, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре белән чиктәш.

Нармонка авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Федоровка һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м, урман массивы буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 2,2 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 100 м, зират буйлап 100 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Үләмә елгасына кадәр 650 м бара, шуннан соң бу елга агымы буенча 350 м өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча 550 м өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, елганың текә сул ярын кисеп үтеп, 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,7 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча 350 м аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көнчыгышка таба, инешне һәм урман полосасын кисеп үтеп, 900 м төньяк-көнбатышка таба бара, көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,1 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне, «Буа – Тәтеш» – Удельное Нечасово – Алекина Поляна автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл кырыендагы урман полосасын кисеп үтеп, 1,4 км уза, аннары «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 47 нче, 46 нчы урман

кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннары 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 41 нче, 42 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км төньяк-көнбатышка таба бара, 37 нче, 36 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 950 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 350 м көнбатышка таба 36 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап Нармонка, Федоровка һәм Келәш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нармонка авыл җирлеге чиге Келәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Келәш һәм Олы Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кушкуй авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 20 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км көньякка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 500 м көньяк-көнчыгышка таба 24 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр 150 м бара, шуннан соң бу инеш агымы буенча 2,4 км аска таба дәвам итә, 36 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк чиге буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нармонка авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Олы Шәмәк һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бисәр авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешләрне берничә тапкыр кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 1,1 км көнбатышка таба «Буа – Тәтеш» – Кушкуй автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап инешкә кадәр уза, моңа кадәр тагын бер инешне кисеп үтә, шуннан соң бу инеш агымы буенча 850 м аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 3,4 км өскә таба бара, 450 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы

18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, 19 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, шуннан соң, 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м көньякка таба уза, көньяк-көнбатышка таба 19 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м һәм 20 нче урман кварталы буйлап 800 м 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нармонка авыл җирлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Льяшево авыл җирлекләре һәм «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Льяшево авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып 500 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба чокыр буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң бу инеш агымы буенча 950 м аска таба уза, сынык сызык ясап, 1,7 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Үләмә елгасына кадәр бара, шуннан соң бу елга агымы буенча 250 м өскә таба бара, аннары 4,0 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нармонка авыл җирлеге чиге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап уза, аннары 500 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 2,3 км урман полосасы буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 50 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 1,9 км аска таба ул Үләмә елгасына койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 200 м өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, шуннан соң бу инеш агымы буенча 1,6 км өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнчыгышка таба яр буендагы урман массивын, кибеп баручы инешне һәм текә ярны кисеп үтеп, 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, Буа – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көнбатышка таба кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, бу инеш агымы буенча 650 м аска таба ул Бизә елгасына койган җиргә кадәр уза, аннары бу инеш агымы буенча 100 м өскә таба аңа коя торган инешнең тамагына кадәр бара, шуннан соң бу инешнең агымы буенча 3,9 км өскә таба аның чишмә башына кадәр уза, аннары 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы

дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м урман массивы буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 250 м 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Нармонка авыл җирлеге, «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Урюм авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Нармонка авыл җирлеге чиге Урюм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман массивы буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп 1,8 км, 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,3 км, урман массивы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 168 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, 168 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр 150 м уза, бу инеш агымы буенча 200 м аска таба кибеп баручы башка инешнең кибә торган ермагы белән кушылган жиргә кадәр бара, шушы кибә торган ермакның агымы буенча 400 м өскә таба кибеп баручы инешнең төп үзәненә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 700 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

8) 30 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
30 нчы кушымта

**Тәтеш муниципаль районының «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сөендек авыл җирлеге Бакырчы, Бидәңге авыл җирлекләре, Буа муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Сөендек авыл җирлеге чиге Бакырчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сөендек, Бакырчы һәм Бидәңге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Бидәңгесе авылыннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, чокырның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, аннары 200 м төньякка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, көнчыгышка таба чокыр буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң 500 м төньяк-көнбатышка таба «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Зөя елгасына кадәр уза, 15 м бу елга буенча Сөендек, Бакырчы авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Татар Чагылдымы авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта Зөя елгасы акваториясендә урнашкан 60 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Сөендек авыл җирлеге чиге Бидәңге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,4 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш – Олы Тархан – Ундоры» – Сөендек автомобиль юлына бүлеп

бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр уза, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап 1,3 км, юлга бүлеп бирелгән шушы полоса буенча, аны кисеп үтеп, 200 м бара, шуннан соң 3,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, Сөендек, Бидәңге авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Башчы авылыннан 2,7 км көньякта урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сөендек авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 68 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Сөендек авыл җирлеге, Буа муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Сөендек авылыннан 4,0 км төньяк-көнбатышта Чынлы елгасы акваториясендә урнашкан 67 нче (4 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Сөендек авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә 67 нче (4 нче) тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап 60 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

9) 32 нче һәм 33 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>32 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урюм авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Жуково, Килдеш, Нармонка, Федоровка авыл җирлекләре, Спас муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Урюм авыл җирлеге чиге Килдеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урюм, Килдеш һәм Жуково авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Берлек авылыннан 950 м төньяк-

көнчыгышта Килнә елгасында урнашкан 46 нчы тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 500 м өскә таба аңа коя торган кибеп баручы инешнең тамагына кадәр уза, шушы инеш агымы буенча 3,0 км өскә таба аның чишмә башына кадәр бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, юл кырыендагы урман полосасын һәм Тәтеш – Олы Тархан – Ундоры автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Урюм участок урманчылыгындагы 2 нче, 4 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км, 98 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Урюм елгасына кадәр 100 м уза, шушы елга агымы буенча 2,2 км өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, яр буендагы агач-куак полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, 12 нче, 20 нче урман кварталлары буйлап 2,6 км уза, аннары 700 м көньяк-көнбатышка таба 20 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 30, 41, 54, 65, 74, 83 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 6,8 км уза, Куйбышев сусаклагычының текә уң яры буйлап 40 м, сусаклагыч акваториясе буйлап 3,0 км Урюм, Килдеш авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Васильевка авылыннан 9,8 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 57 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урюм авыл җирлеге чиге Жуково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урюм, Жуково һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 3,8 км көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км көньякка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,3 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буендагы агач-куак массивын кисеп үтеп, 500 м Килнә елгасына кадәр бара, шуннан соң бу елга агымы буенча 2,3 км аска таба 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урюм, Федоровка һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 4,2 км төньяк-

көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урюм, Нармонка авыл җирлекләре һәм «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман массивы буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп 1,8 км, 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,3 км, урман массивы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 168 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, 168 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр 150 м уза, бу инеш агымы буенча 200 м аска таба кибеп баручы башка инешнең кибә торган ермагы белән кушылган җиргә кадәр бара, шушы кибә торган ермакның агымы буенча 400 м өскә таба кибеп баручы инешнең төп үзәненә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 700 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Урюм авыл җирлеге, «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тәтеш шәһәреннән 850 м көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 25 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба, сусаклагычның текә уң ярын кисеп үтеп, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 850 м, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 78 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м уза, аннары көньякка таба 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 200 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап 100 м, 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 400 м бара, шуннан соң 250 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 79 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км көньякка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 83 нче, 82 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 550 м уза, күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 82 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 м бара, Тәтеш – Олы Тархан – Ундоры автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м уза, аны кисеп үтә һәм 81 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары 1,6 км төньяк-көнбатышка таба 81 нче, 80 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 650 м көньяк-көнбатышка таба 80 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба 80 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 169 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, урман массивын кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Урюм авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Урюм авыл җирлеге, Спас муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 8,5 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 50 нче (3 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 50 нче (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасының административ чиге буйлап 57 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
33 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының «Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Федоровка авыл җирлеге Жуково, Келәш, Кошки-Новотимбаево, Нармонка, Урюм авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.

Федоровка авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә Федоровка, Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Федоровка, Келәш авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Федоровка авыл җирлеге чиге Келәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Федоровка, Келәш һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 35 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Федоровка авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Федоровка, Нармонка һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне

кисеп үтеп, 300 м, урман массивы буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 2,2 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 100 м, зират буйлап 100 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Үләмә елгасына кадәр 650 м бара, шуннан соң бу елга агымы буенча 350 м өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча 550 м өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, елганың текә сул ярын кисеп үтеп, 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,7 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча 350 м аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көнчыгышка таба, инешне һәм урман полосасын кисеп үтеп, 900 м төньяк-көнбатышка таба бара, көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,1 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне, «Буа – Тәтеш» – Удельное Нечасово – Алекина Поляна автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл кырыендагы урман полосасын кисеп үтеп, 1,4 км уза, аннары «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 47 нче, 46 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннары 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 41 нче, 42 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км төньяк-көнбатышка таба бара, 37 нче, 36 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 950 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 350 м көнбатышка таба 36 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Федоровка авыл җирлеге чиге Жуково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Федоровка, Жуково һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 3,8 км көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м

уза, шуннан соң «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 1,1 км, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, инешләрне һәм кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 1,5 км уза, шуннан соң көнбатышка таба урман массивының көньяк чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, Жуково һәм Кызыл Йолдыз авылларын тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр 1,8 км уза, шушы инеш агымы буенча 1,0 км аска таба башка кибеп баручы инешкә койган җиргә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча 3,0 км өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 250 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, шуннан соң «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км Федоровка, Жуково һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Федоровка авыл җирлеге чиге Урюм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 22 ноябре
№ 99-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1202. «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 – 6 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Спас муниципаль районы Ульяновск өлкәсе, Тәтеш, Кама Тамагы, Лаеш, Алексеевск һәм Әлки муниципаль районнары белән чиктәш.

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Әлки, Спас муниципаль районнарының һәм Ульяновск өлкәсенең чикләре тоташкан урында Нәлет авылыннан 300 м көньяк-көнчыгышка таба урнашкан 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас, Тәтеш муниципаль районнарының һәм Ульяновск өлкәсенең чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасына кадәр сузыла.

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Кама Тамагы, Спас һәм Тәтеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасыннан алып «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 140, 131, 123 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 5,4 км төньяк-көнчыгышка, 8 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м уза, аннары 8 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 50 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, алга таба әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,6 км Юхмачы елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 750 м, 5 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 20 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 400 м, көньяк-көнбатышка 250 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 110, 121, 120, 119, 118 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 6,8 км уза, Майна елгасын һәм Барановский инешен кисеп үтеп, 118, 105, 92 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 7,0 км төньяк-көнбатышка уза, аннары 92, 80, 73 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 3,0 км бара, 73 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, 500 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,7 км, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 32 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка

1,4 км һәм көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 700 м бара, 30 нчы, 31 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча 750 м көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 32 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш, көньяк һәм көнбатыш чикләре һәм 31 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка 2,1 км бара, аннары 31 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 1,4 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 850 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап төньякка 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м, урман массивының көнбатыш чиге буенча 250 м бара, тагын авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м, урман массивы буенча кибеп баручы инешкә кадәр 200 м уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча буага кадәр 400 м дәвам итә, аннары буа буйлап төньяк-көнчыгышка 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча тагын аска таба 4,4 км аның Утка елгасына кушылган җиренә кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 450 м уза, яр буендагы агач-куаклыклар полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 800 м бара, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, Югары Колчурино – Катюшино автомобиль юлын һәм Кузнечиха авылына керү юлын тоташтыра торган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 200 м, 14 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 1,2 км бара, алга таба 14 нче, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 2,6 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, урман массивы буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 900 м һәм, сынык сызык ясап, көнбатышка 400 м, сынык сызык ясап, чокыр төбе буенча төньяк-көнбатышка 650 м дәвам итә, кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 1,6 км, чокыр кырыен кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 100 м бара, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, 6 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 1,3 км бара, аннары урман массивы буенча төньяк-көнчыгышка 20 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча төньякка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча 150 м, 75 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча

төньяк-көнчыгышка 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 350 м дәвам итә, алга таба яңадан әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 1,0 км, урман полосасы буенча 150 м бара, аннары урман полосасының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 50 м, урман полосасы буенча 600 м бара, аннары, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка» – Фадеевка һәм Кошки – Чуаш Шәпкәсе автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м уза, урман полосасы буенча 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, Бездна елгасының сулъяк ярындагы кыялы кишәрлекне һәм елганың үзен кисеп үтеп, кибеп баручы инеш борынына кадәр авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, аннары әлеге инеш агымы буенча өскә таба 1,8 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 700 м һәм төньяк-көнбатышка 25 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 700 м төньяк-көнбатышка һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 2,4 км, Тахтала инешен һәм чокырларны кисеп үтеп, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буенча 400 м бара, сынык сызык ясап, төньякка «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 400 м төньякка уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 250 м һәм көнбатышка 200 м, урман массивы буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка урман утыртмаларының төньяк чиге буенча 1,1 км, 86 нчы, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча 2,2 км уза, алга таба төньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 84 нче, 85 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча 1,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 750 м уза, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка 1,3 км, урман массивы буенча төньякка 15 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман массивы буенча 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман массивы буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, 75, 76, 77 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,7 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 78 нче, 74 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка

1,8 км, 74 нче, 73 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 3,5 км бара, алга таба 73 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 71 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча төньякка 1,8 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 450 м, сынык сызык ясап, 69 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 500 м бара, алга таба, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 6,0 км уза, аннары урман массивы буенча төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, төньяк-көнчыгышка 1,3 км һәм төньяк-көнбатышка 500 м, 56 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 3,5 км Әлки, Алексеевск, Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 5,8 км төньяк-көнчыгышта, үләт чокырыннан 0,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,6 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 3,5 км, көнбатышка 950 м, төньяк-көнбатышка 550 м, төньяк-көнчыгышка 6,2 км, төньяк-көнбатышка 450 м уза, аннары күл буенча 100 м бара, алга таба кабат авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 300 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка Актай елгасына кадәр 700 м уза, аннары әлеге елга агымы буенча аска таба 3,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, чокырлы кишәрлекләрне, чокырларны һәм Актай елгасын кисеп үтеп, 3,2 км уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 250 м, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 950 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2 нче, 3 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнчыгышка 2,1 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 3 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буенча төньяк-көнбатышка 2,1 км уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Алексеевск, Спас һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 11,6 км төньяк-көнчыгышта

Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 24 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 24 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча көньяк-көнбатышка 26,0 км, сынык сызык ясап, Кама Тамагы, Лаеш һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 12,1 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 20 нче (33 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче (33 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>3 нче кушымта

### Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре, Кама Тамагы һәм Тәтеш муниципаль районнары белән чиктәш.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге, Өчкүл авыл җирлеге һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,3 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге, Тәтеш һәм Кама Тамагы муниципаль районнары чикләре тоташкан

урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (34 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге, Приволжский авыл җирлеге һәм Кама тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 7,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньякка 8,4 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча сулъяк ярга кадәр уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 200 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырларны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көнбатышка 350 м, көньяк-көнчыгышка 100 м аэродромга кадәр бара, аэродром буенча көньяк-көнчыгышка 650 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 650 м, төньяк-көнчыгышка 700 м, саклау валын һәм «Базарлы Матак — Болгар» — Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка 1,0 км, көньяк-көнбатышка 150 м уза, аннары көньякка урман массивының көнбатыш чиге буенча 150 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка, урман массивын һәм сакланулы урман полосасын кисеп үтеп, Базарлы Матак — Болгар автомобиль юлына кадәр 750 м бара, аннары әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча көнчыгышка 600 м, алга таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 300 м «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге, Приволжский һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 3,1 км көньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 50 м, урман массивының төньяк чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча Болгар — Танкеевка автомобиль юлына кадәр 1,2 км бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча көньякка 750 м уза, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 350 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 29 нчы

урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка 1,3 км һәм 28 нче урман кварталы буйлап 1,7 км бара, аннары 28 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 2,5 км уза, алга таба 14, 13, 12 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка 3,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр уза, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 2,0 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>4 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Аграмак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Аграмак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Аграмак авыл җирлеге Антоновка, «КИМ», Урта Йорткүл, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы белән чиктәш.

Аграмак авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Аграмак, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 4,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Аграмак, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аграмак авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 150 м Аграмак, Урта Йорткүл һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Аграмак авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка 1,4 км бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, урман полосасы буйлап 500 м бара, алга таба, ике тапкыр сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,0 км, көнбатышка 1,0 км, Антоновка – Татар Такталысы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 2,7 км, Наясолка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 2,6 км һәм төньяк-көнбатышка 400 м уза, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 1,4 км Аграмак, Антоновка һәм «КИМ» авыл җирлекләре тоташкан урында Тукай авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Аграмак авыл җирлеге чиге «КИМ» авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аграмак, «КИМ», Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка 3,1 км Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлы буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 450 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 700 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 1,3 км 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аграмак авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып 3,5 км төньяк-көнбатышка Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 3,5 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м бара, алга таба «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньякка 650 м һәм көньяк чиге буенча көнбатышка 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 550 м, төньяк-көнбатышка 100 м бара, аннары 65 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 950 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 250 м, көнбатыш чиге буйлап көньякка 200 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 350 м уза, алга таба, урман массивын, урман полосасын һәм Аграмак – Ямбакты автомобиль

юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,1 км бара, шуннан соң 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап көньякка 400 м, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м уза, аннары әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньякка 350 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 450 м дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м бара, аннары 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км һәм, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Антоновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Антоновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Антоновка авыл җирлеге Аграмак, «КИМ», Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре белән чиктәш.

Антоновка авыл җирлеге чиге «КИМ» авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Антоновка, «КИМ» һәм Аграмак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 200 м, алга таба көнбатышка

авыл хуҗалыгы җирләре буенча 800 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 500 м «Алексеевск – Югары Колок» – Базяково – Тукай автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м бара, аннары көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 150 м һәм, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,4 км уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 300 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 1,4 км, көньяк-көнчыгышка 150 м һәм кабат көньяк-көнбатышка 450 м Антоновка, «КИМ» һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында «КИМ» совхозының икенче ферма поселогыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Антоновка авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Антоновка, Аграмак һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,4 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, урман полосасы буйлап 500 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, ике тапкыр сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка 1,0 км, көнбатышка 1,0 км, Антоновка – Татар Такталысы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 2,7 км, Наясолка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 2,6 км һәм төньяк-көнбатышка 400 м уза, аннары төньяк-көнбатышка 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Антоновка авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км, «Әлки

урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м бара, Бездна елгасын, яр буе агач-куак массивын, сазлыкны һәм «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча Антоновка, Урта Йорткүл һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан җирдә Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Антоновка авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, сазлык буйлап 200 м, күл буйлап 100 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка сазлык буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасы буенча 2,5 км, сазлык буйлап 100 м Лахтур инешенә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 450 м аска таба буага кадәр уза, әлеге буаның уңъяк яры буйлап төньяк-көнбатышка 2,8 км бара, алга таба «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м уза, аннары төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 700 м бара, алга таба 40 нчы, 41 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 2,2 км уза, аннары 41, 39, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,4 км төньяк-көнбатышка 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта

**Спас муниципаль районының «Бураково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Бураково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бураково авыл җирлеге Әҗмәр, Ямбакты авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Лаеш муниципаль районнары белән чиктәш.

Бураково авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бураково, Әҗмәр авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 7,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Бураково авыл җирлеге, Лаеш һәм Алексеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 11,6 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 24 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Бураково авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 24 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Бураково, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 3,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Бураково авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,2 км, көньякка 650 м, төньяк-көнбатышка 250 м уза, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 850 м һәм көнбатыш чиге буенча көньякка 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы

җирләре буенча көньякка 200 м, көньяк-көнбатышка 400 м, төньякка 2,0 км, көнбатышка 1,4 км урман полосасына кадәр уза, әлеге урман полосасының көньяк чиге буенча көнбатышка 450 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 700 м, урман массивын кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка Бураково, Ямбакты һәм Әҗмәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 5,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бураково авыл җирлеге чиге Әҗмәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 8,5 км аның сулъяк ярына кадәр уза, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 20 нче, 21 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,9 км бара, алга таба көньяк-көнбатышка 21 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, аннары 21 нче, 22 нче урман кварталлары буенча көньяк-көнбатышка 600 м, көньяк-көнчыгышка 1,3 км дәвам итә, шуннан соң көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, канауны кисеп үтеп, Актай елгасына кадәр 650 м уза, әлеге елга агымы буенча 1,4 км аска таба аңа Сушка елгасы койган җиргә кадәр бара, Сушка елгасы агымы буенча, «Алексеевск – Югары Колок» – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 9,0 км өскә таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м өскә таба һәм кабат Сушка елгасы агымы буенча 650 м өскә таба 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

2) 8 – 20 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Әҗмәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Әҗмәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас

муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әҗмәр авыл җирлеге Бураково, Куралово, Ямбакты авыл җирлекләре, Кама Тамагы һәм Лаеш муниципаль районнары белән чиктәш.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Әҗмәр, Куралово авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 7,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=405887,08, Y=1324434,98 координаталы 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Әҗмәр авыл җирлеге, Кама Тамагы һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 12,1 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 20 нче (33 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче (33 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Әҗмәр, Бураково авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 7,7 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Бураково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 8,5 км аның сулъяк ярына кадәр уза, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 20 нче, 21 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,9 км бара, алга таба көньяк-көнбатышка 21 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, шуннан соң 21 нче, 22 нче урман кварталлары буенча көньяк-көнбатышка 600 м, көньяк-көнчыгышка 1,3 км дәвам итә, аннары көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, канауны кисеп үтеп, Актай елгасына кадәр 650 м уза, әлеге елга агымы буенча 1,4 км аска таба аңа Сушка елгасы койган җиргә кадәр бара, Сушка елгасы агымы буенча, «Алексеевск — Югары Колок» — Базяково — Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 9,0 км өскә таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м өскә таба һәм кабат Сушка елгасы агымы буенча 650 м өскә таба Әҗмәр, Бураково һәм Ямбакты авыл җирлекләре чикләре то-

ташкан урында Ямбакты авылыннан 5,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, урман полосасы буенча 450 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м Әҗмәр, Ямбакты һәм Куралово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 4,4 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Куралово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 12,2 км көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап сусаклагычка инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м, сазлыкның төньяк чиге буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м Әҗмәр авылына керә торган юлга кадәр уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап көньякка 1,6 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 950 м һәм көньяк чиге буйлап көнчыгышка 1,5 км дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,1 км көньяк-көнбатышка һәм 1,4 км көньяк-көнчыгышка 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

## Спас муниципаль районының «Иске Рәҗәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Рәҗәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге Чәчәкле авыл җирлеге, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Иске Рәҗәп, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Рәҗәп авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Иске Рәҗәп авыл җирлеге, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Нәлет авылыннан 300 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Иске Рәҗәп, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Чәчәкле авылыннан 4,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге чиге Чәчәкле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 104, 103, 102, 101, 100, 99, 98 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнбатышка 6,9 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км, көньяк-көнбатышка 50 м бара, аннары көньяк-көнбатышка 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомо-

биль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м һәм 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

## Спас муниципаль районының «КИМ» авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «КИМ» авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«КИМ» авыл җирлеге Аграмак, Антоновка, Куралово, Кызыл Бистә, Никольский, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә «КИМ», Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,4 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 397798,59, Y = 1315465,17 координаталы 11 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буенча «КИМ», Куралово авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 403480,35, Y = 1320216,74 координаталы 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Куралово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, сынык сызык ясап, көньяк-

көнчыгышка Утюшка елгасы тамагына кадәр 15,3 км бара, аннары әлеге елга агымы буенча 6,1 км өскә таба бара, аннары көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 850 м, «Алексеевск – Югары Колок» – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,4 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 1,9 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка «КИМ», Куралово һәм Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ярдәм поселогыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,5 км көньяк-көнчыгышка һәм, урман полосасын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буйлап 800 м көньяк-көнбатышка «КИМ», Ямбакты һәм Аграмак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка Болгар – Базарлы Матак автомобиль юлы буйлап 3,1 км уза, аннары көньякка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 450 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 700 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км көньяк-көнбатышка «КИМ», Аграмак һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 200 м, алга таба көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 800 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 500 м «Алексеевск – Югары Колок» – Базяково – Тукай автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м бара, аннары көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 150 м,

авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 150 м һәм, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,4 км уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 300 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 1,4 км, көньяк-көнчыгышка 150 м һәм кабат көньяк-көнбатышка 450 м «КИМ», Антоновка һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында «КИМ» совхозының икенче ферма поселогыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м уза, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка 150 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 400 м бара, алга таба көньяк-көнбатышка, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, кабат әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 700 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 600 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 50 м, төньяк-көнбатышка 200 м уза, аннары әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 300 м уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 550 м һәм, сазлыкны һәм Бездна елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 400 м уза, алга таба 33 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка 50 м һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча төньякка 1,1 км бара, аннары төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, 33 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 250 м инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, алга таба төньяк-көнбатышка күл буенча 200 м, инеш агымы буенча 150 м аска таба, күл буенча 50 м, кабат инеш агымы буенча 1,4 км аска таба аның Куйбышев сусаклагычына койган җиренә кадәр бара, әлеге сусаклагычның

сулъяк яры буйлап 850 м төньяк-көнбатышка «КИМ», Никольский һәм Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширбәт авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«КИМ» авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы буйлап утрауга кадәр 9,4 км уза, әлеге утрауның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,6 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 2,6 км бара, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1,4 км көньякка сулъяк ярга кадәр бара һәм Куйбышев сусаклагычының сулъяк яры буйлап 9,5 км көньяк-көнбатышка 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Кызыл Бистә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кызыл Бистә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кызыл Бистә авыл җирлеге «КИМ», Никольский, Полянка, Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре, Кама Тамагы муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кызыл Бистә, Приволжский авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ржавец авылыннан 9,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 397116,91, Y = 1310102,39 координаталы 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Кызыл Бистә, «КИМ» авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы

чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,4 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 397798,59, Y = 1315465,17 координаталы 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге «КИМ» авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы буйлап утрауга кадәр 9,4 км уза, әлеге утрауның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,6 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 2,6 км бара, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1,4 км көньякка сулъяк ярга кадәр бара һәм Куйбышев сусаклагычының сулъяк яры буйлап 9,5 км көньяк-көнбатышка Кызыл Бистә, «КИМ» һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширбәт авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып Ясачка елгасы агымы буенча 1,5 км өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча өскә таба 500 м бара, көньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м уза, аннары көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 650 м, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 25, 26, 27 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 5,3 км, сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча сазлыкка кадәр 450 м бара, алга таба әлеге сазлыкның көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 200 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча уза, аннары көньяк-көнбатышка сазлык буйлап 950 м, берничә тапкыр сазлыкны һәм ике тапкыр урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км бара, сазлык буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка, 1,1 км көньяк-көнчыгышка, 400 м төньяк-көнчыгышка һәм 1,2 км көньяк-көнчыгышка Кызыл Бистә, Никольский авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Бугровка авылыннан 4,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Рес-

публикасы административ чиге буйлап Кызыл Бистә, Полянка авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Полянка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кызыл Бистә, Полянка һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км көньяк-көнбатышка 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кызыл Бистә, Өчкүл һәм Приволжский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көньяк-көнчыгышка 900 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 5,3 км 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, сынык сызык ясап, көньякка 9,5 км сулъяк ярга кадәр уза, алга таба көньякка «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 49, 58, 65 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 3,4 км, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м бара, аннары 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 450 м уза, алга таба көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м уза, аннары урман полосасының көньяк чиге буйлап 950 м көнбатышка бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 900 м, көньяк-көнбатышка 350 м Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буенча төньяк-көнбатышка 3,0 км бара, аннары көньяк-көнбатышка, дамбаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Кузнечиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кузнечиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кузнечиха авыл җирлеге Урта Йорткүл, Чәчәкле авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Йорткүл авылыннан 5,1 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Кузнечиха, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Йолдыз авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Чәчәкле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 550 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,8 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 200 м, төньяк-көнбатышка 300 м бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, чокыр төбе буйлап 800 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 1,3 км чокырларны кисеп уза, канау буенча 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 300 м, көньяк-көнчыгышка 200 м бара, шуннан соң «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреж-

дениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 83 урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 50 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м, урман полосасы буйлап 650 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м Кузнечиха, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Покровка авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Покровка авылыннан 3,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,2 км, көнбатышка 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 350 м, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м уза, урман полосасының көньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,1 км һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 100 м, ярның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, ике тапкыр чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,8 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, көньякка 1,3 км, төньяк-көнбатышка 1,8 км, көньякка 750 м бара, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,0 км, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, урман массивы буенча 150 м бара, шуннан соң урман массивы буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

### Спас муниципаль районының «Куралово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Куралово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Куралово авыл җирлеге Әҗмәр, «КИМ», Ямбакты авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

Куралово авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Куралово, «КИМ» авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=403480,35, Y=1320216,74 координаталы 14 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буенча Куралово, Әҗмәр авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 7,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=405887,08, Y = 1324434,98 координаталы 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Куралово авыл җирлеге чиге Әҗмәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 12,2 км көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап сусаклагычка инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м, сазлыкның төньяк чиге буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м Әҗмәр авылына керә торган юлга кадәр уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап көньякка 1,6 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-

көнбатыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 950 м һәм көньяк чиге буйлап көнчыгышка 1,5 км дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,1 км көньяк-көнбатышка һәм 1,4 км көньяк-көнчыгышка Куралово, Әҗмәр һәм Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 4,4 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Куралово авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 200 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,8 км Куралово, Ямбакты һәм «КИМ» авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ярдәм поселогыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Куралово авыл җирлеге чиге «КИМ» авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка Утюшка елгасы тамагына кадәр 15,3 км бара, аннары әлеге елга агымы буенча 6,1 км өскә таба бара, аннары көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 850 м, «Алексеевск – Югары Колок» – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,4 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 1,9 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>14 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-

схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Никольский авыл җирлеге Антоновка, «КИМ», Кызыл Бистә, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Никольский авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча Никольский, Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Бугровка авылыннан 4,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Никольский авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никольский, Кызыл Бистә һәм «КИМ» авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширбәт авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып Ясачка елгасы агымы буенча 1,5 км өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча өскә таба 500 м бара, көньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м уза, аннары көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 650 м, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 25, 26, 27 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 5,3 км, сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча сазлыкка кадәр 450 м бара, алга таба әлеге сазлыкның көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 200 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча уза, аннары көньяк-көнбатышка сазлык буйлап 950 м, берничә тапкыр сазлыкны һәм ике тапкыр урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км бара, сазлык буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка, 1,1 км көньяк-көнчыгышка, 400 м төньяк-көнчыгышка һәм 1,2 км көньяк-көнчыгышка 13 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

Никольский авыл җирлеге чиге «КИМ» авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никольский, «КИМ» һәм Антоновка авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында «КИМ» совхозының икенче фермасы поселогыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м уза, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка 150 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 400 м бара, алга таба көньяк-көнбатышка, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, кабат әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 700 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 600 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 50 м, төньяк-көнбатышка 200 м уза, аннары әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 300 м уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 550 м һәм, сазлыкны һәм Бездна елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 400 м уза, алга таба 33 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка 50 м һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча төньякка 1,1 км бара, аннары төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, 33 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 250 м инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, алга таба төньяк-көнбатышка күл буенча 200 м, инеш агымы буенча 150 м аска таба, күл буенча 50 м, кабат инеш агымы буенча 1,4 км аска таба аның Куйбышев сусаклагычына койган җиренә кадәр бара, әлеге сусаклагычның сулъяк яры буйлап 850 м төньяк-көнбатышка 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Никольский авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Никольский һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, сазлык буйлап 200 м, күл буйлап 100 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка сазлык буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман

полосасы буенча 2,5 км, сазлык буйлап 100 м Лахтур инешенә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 450 м аска таба буага кадәр уза, әлеге буаның уңъяк яры буйлап төньяк-көнбатышка 2,8 км бара, алга таба «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м уза, аннары төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 700 м бара, алга таба 40 нчы, 41 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 2,2 км уза, аннары 41, 39, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,4 км төньяк-көнбатышка 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Никольский авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 600 м, чокырны, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка» – Кырый Йорткүл – «Никольский – Отрада» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, сазлыкны кисеп үтеп, көнбатышка 3,1 км һәм төньякка 200 м 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Полянка авыл җирлеге Кызыл Бистә, Өчкүл авыл җирлекләре, Тәтеш муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Полянка авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Полянка, Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Полянка авыл җирлеге, Тәтеш муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Полянка авыл җирлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буенча Полянка, Өчкүл авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,6 км көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Полянка авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Полянка, Өчкүл һәм Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 3,4 км төньяк-көнбатышка кибеп баручы инешкә кадәр үтә, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча өскә таба 150 м уза, аннары күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,0 км плотинага кадәр дәвам итә, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, плотинаны төньяк-көнчыгыш ягыннан әйләнеп узып, 50 м бара, буаның сулъяк яры буйлап көнбатышка 50 м уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба күлгә кадәр 400 м, күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча кабат өскә таба күлгә кадәр 250 м уза, күл буйлап төньяк-көнбатышка 50 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 3,6 км дәвам итә, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км уза, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, төньяк-көнчыгышка 800 м Өчкүл – Балымер автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, төньяк-көнбатышка 1,6 км һәм көнбатышка 1,1 км бара, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас

участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап көнбатышка 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м, 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м бара, шуннан соң 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 500 м уза, алга таба 37 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,2 км һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка 1,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр дәвам итә, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 3,7 км көнбатышка 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Полянка авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 400 м бара, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 1,1 км 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>16 нчы кушымта

## Спас муниципаль районының «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Приволжский авыл җирлеге «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге, Кызыл Бистә, Өчкүл авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

Приволжский авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Приволжский авыл җирлеге, «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 7,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль рай-

оны чиге буйлап Приволжский, Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ржавец авылыннан 9,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=397116,91, Y=1310102,39 координаталы 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, сынык сызык ясап, көньякка 9,5 км сулъяк ярга кадәр уза, алга таба көньякка «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 49, 58, 65 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 3,4 км, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м бара, аннары 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 450 м уза, алга таба көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м уза, аннары урман полосасының көньяк чиге буйлап 950 м көнбатышка бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 900 м, көньяк-көнбатышка 350 м Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буенча төньяк-көнбатышка 3,0 км бара, аннары көньяк-көнбатышка, дамбаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Приволжский, Кызыл Бистә һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 2,0 км, төньяк-көнбатышка 250 м урман полосасына кадәр бара, әлеге урман полосасының көнбатыш чиге буйлап төньякка 1,5 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 950 м Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре һәм «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 3,1 км көньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньякка 8,4 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча сулъяк ярга кадәр уза, анна-

ры авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 200 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырларны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көнбатышка 350 м, көньяк-көнчыгышка 100 м аэродромга кадәр бара, аэродром буенча көньяк-көнчыгышка 650 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 650 м, төньяк-көнчыгышка 700 м, саклау валын һәм «Базарлы Матак – Болгар» – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка 1,0 км, көньяк-көнбатышка 150 м уза, аннары урман массивының көнбатыш чиге буенча көньякка 150 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка, урман массивын һәм сакланулы урман полосасын кисеп үтеп, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр 750 м бара, аннары әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча көнчыгышка 600 м уза, алга таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 300 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Урта Йорткүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урта Йорткүл авыл җирлеге Аграмак, Антоновка, Кузнечиха, Никольский авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кузнечиха авылыннан 4,9 км көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасын-

нан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Антоновка һәм Никольский авыл җирлекләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 600 м, чокырны, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка» – Кырый Йорткүл – «Никольский – Отрада» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, сазлыкны кисеп үтеп, көнбатышка 3,1 км һәм төньякка 200 м 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Антоновка һәм Аграмак авыл җирлекләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м бара, Бездна елгасын, яр буе агач-куак массивын, сазлыкны һәм «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Аграмак авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Урта Йорткүл, Кузнечиха авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Йорткүле авылыннан 5,1 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Кузнечиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,2 км, көнбатышка 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 350 м, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м уза, урман полосасының көньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,1 км һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 100 м, ярның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, ике тапкыр чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,8 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, көньякка 1,3 км, төньяк-көнбатышка 1,8 км, көньякка 750 м бара, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,0 км, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, урман массивы буенча 150 м бара, шуннан соң урман массивы буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
18 нче кушымта

### Спас муниципаль районының «Өчкүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Өчкүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Өчкүл авыл җирлеге «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге, Кызыл Бистә, Полянка, Приволжский авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Өчкүл, Полянка авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,6 км көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Өчкүл авыл җирлеге, «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,3 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Өчкүл авыл җирлеге, «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Приволжский авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 3,1 км көньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 50 м, урман массивының төньяк чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча Болгар – Танкеевка автомобиль юлына кадәр 1,2 км бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча көньякка 750 м уза, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 350 м бара, аннары, сынык сызык ясап, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка 1,3 км, 28 нче урман кварталы буйлап 1,7 км бара, аннары 28 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча 2,5 км төньяк-көнбатышка уза, алга таба 14, 13, 12 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка 3,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр уза, сусаклагыч акваториясе буйлап 2,0 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Өчкүл, Приволжский, Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 2,0 км, төньяк-көнбатышка 250 м урман полосасына кадәр бара, шуннан соң әлеге урман полосасының көнбатыш чиге буйлап төньякка 1,5 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 950 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көньяк-көнчыгышка 900 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 5,3 км Өчкүл, Кызыл Бистә һәм Полянка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Полянка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 3,4 км төньяк-көнбатышка кибеп баручы инешкә кадәр үтә, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча өскә таба 150 м уза, аннары күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,0 км плотинага кадәр дәвам итә, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, плотинаны төньяк-көнчыгыш ягыннан әйләнеп узып, 50 м бара, буаның сулъяк яры буйлап көнбатышка 50 м уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба күлгә кадәр 400 м, күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча кабат өскә таба күлгә кадәр 250 м уза, күл буйлап төньяк-көнбатышка 50 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 3,6 км дәвам итә, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км уза, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, төньяк-көнчыгышка 800 м Өчкүл – Балымер автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, төньяк-көнбатышка 1,6 км һәм көнбатышка 1,1 км бара, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап көнбатышка 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м, 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м бара, шуннан соң 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 500 м уза, алга таба 37 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,2 км һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка 1,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына

кадәр дәвам итә, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 3,7 км көнбатышка 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
19 нчы кушымта

**Спас муниципаль районының «Чәчәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Чәчәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чәчәкле авыл җирлеге Иске Рәҗәп, Кузнечиха авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Чәчәкле, Кузнечиха авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Йолдыз авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Чәчәкле, Иске Рәҗәп авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Рәҗәп авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Иске Рәҗәп авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 104, 103, 102, 101, 100, 99, 98 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнбатышка 6,9 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км, көньяк-көнбатышка 50 м бара, аннары көньяк-көнбатышка 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап

650 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км Чәчәкле, Иске Рәҗәп авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Чәчәкле авылыннан 4,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Чәчәкле, Кузнечиха авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Покровка авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Кузнечиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 550 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,8 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 200 м, төньяк-көнбатышка 300 м бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, чокыр төбе буйлап 800 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 1,3 км чокырларны кисеп уза, канау буенча 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 300 м, көньяк-көнчыгышка 200 м бара, шуннан соң «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 83 урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 50 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м, урман полосасы буйлап 650 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Спас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

## Спас муниципаль районының «Ямбакты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Ямбакты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ямбакты авыл җирлеге Аграмак, Бураково, Әҗмәр, «КИМ», Куралово авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Әлки муниципаль районнары белән чиктәш.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ямбакты, Бураково авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 3,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Ямбакты авыл җирлеге, Алексеевск һәм Әлки муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 5,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Ямбакты, Аграмак авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 4,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып 3,5 км төньяк-көнбатышка Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 3,5 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м бара, алга таба «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньякка 650 м һәм көньяк чиге буенча көнбатышка 100 м уза,

шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 550 м, төньяк-көнбатышка 100 м бара, аннары 65 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 950 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 250 м, көнбатыш чиге буйлап көньякка 200 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 350 м уза, алга таба, урман массивын, урман полосасын һәм Аграмак – Ямбакты автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,1 км бара, шуннан соң 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап көньякка 400 м, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м уза, аннары әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньякка 350 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 450 м дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м бара, аннары 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км һәм, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м Ямбакты, Аграмак һәм «КИМ» авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге «КИМ» авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямбакты, «КИМ» һәм Куралово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ярдәм поселогыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,5 км көньяк-көнчыгышка һәм 1,2 км көньяк-көнбатышка, урман полосасын кисеп үтеп, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап көньяк-көнбатышка 800 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Куралово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямбакты, Куралово һәм Әҗмәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 4,4 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 200 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,8 км 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Әҗмәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямбакты, Әҗмәр һәм Бураково авыл җирлекләре чикләре то-

ташкан урында Ямбакты авылыннан 5,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 650 м бара, чокырны кисеп чыгып, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, урман полосасы буенча 450 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Бураково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,2 км, көньякка 650 м, төньяк-көнбатышка 250 м уза, аннары «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 850 м һәм көнбатыш чиге буенча көньякка 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 200 м, көньяк-көнбатышка 400 м, төньякка 2,0 км, көнбатышка 1,4 км урман полосасына кадәр уза, әлеге урман полосасының көньяк чиге буенча көнбатышка 450 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 700 м, урман массивын кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 22 ноябре
№ 100-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1203. «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, №1 (II өлеш), 2008, № 12 (IV өлеш), 2010, № 5 (I өлеш), 2 – 32 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кукмара муниципаль районы Киров өлкәсе, Удмурт Республикасы, Балтач, Саба, Мамадыш һәм Теләче муниципаль районнары белән чиктәш.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Киров өлкәсе һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Кукмара, Балтач муниципаль районнары һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Югары Китәк поселогыннан 1,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (14 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Кукмара, Мамадыш муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Лубян авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 55 нче (15 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 1 нче (14 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап сынык сызык белән 800 м көньяк-көнбатышка таба, Зур Китячка елгасын кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнчыгышка таба 1 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, аннары «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 250 м көньякка таба, 600 м көньяк-көнбатышка таба «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 19-К урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 21-К урман кварталының көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр уза, аннары 1,0 км көнбатышка таба әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап, 250 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 450 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 200 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 9 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр, 500 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 9 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,2 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 18 нче урман кварталының көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба сынык сызык белән 1,9 км көньякка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 18 нче, 22 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 650 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл

Зур Сәрдек авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 64 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, 1,1 км инеш агымы буенча аска таба Норма елгасына кадәр бара, 1,8 км әлеге елга агымы буенча аска таба буага кадәр уза, алга таба 750 м төньякка таба буа буйлап плотинага кадәр бара, аннары 100 м көнчыгышка таба плотинаның көньяк чиге буйлап бара, 1,4 км Норма елгасы агымы буенча аска таба Зур Сәрдек авылын әйләнеп узучы автомобиль юлына кадәр уза, алга таба 650 м төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап Бөр елгасына кадәр бара, 2,3 км бу елга агымы буенча өскә таба уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба чокырлы сул ярның төньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 350 м аның агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң 800 м төньяк-көнбатышка таба чокырның көньяк кырые буйлап, чокырны кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап уза, аннары 1,0 км көньяк-

көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Зур Сәрдек, Олыяз һәм Сәрдекбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зур Сәрдек авыл җирлеге чиге Сәрдекбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Кукмара – Шәмәрдән» – Янсыбы – Зур Сәрдек – Тырыш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Барбыш елгасына кадәр уза, 650 м бу елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң 50 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, чокырны һәм урман массивын кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м 16 нчы урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 16 нчы урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 700 м төньяк-көнчыгышка урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 11 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Зур Сәрдек, Сәрдекбаш авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Каенлык авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Сәрдек авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Важашур авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Важашур авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Важашур авыл җирлеге Кәркәүч, Түбән Өскебаш, Түбән Үрәс, Пүчинкә-Кучук, Пычак авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш. Важашур авыл җирлеге чиге Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Важашур, Пүчинкә-Кучук һәм Түбән Үрәс авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Октябрь авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Кәркәүч – Сасмак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Важашур, Пүчинкә-Кучук һәм Пычак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Каенсар авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Важашур авыл җирлеге чиге Пычак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Важашур, Пычак авыл

җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Югары Шөн авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Важашур авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып, Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Важашур, Кәркәүч авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Салтык Ерыклы авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Важашур авыл җирлеге чиге Кәркәүч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инешнең чокырлы уң ярын кисеп үтеп, 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, аның чокырлы сул ярын кисеп үтеп, 550 м инеш агымы буенча аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, 500 м бу инеш агымы буенча аска таба аңа икенче инеш койган җиргә кадәр уза, 350 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 800 м көньякка таба чокыр төбеннән уза, алга таба 550 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Важашур, Кәркәүч һәм Түбән Өскебаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шөн авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Важашур авыл җирлеге чиге Түбән Өскебаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып сынык сызык белән 2,3 км көньяк-көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лубян участок урманчылыгындагы 117, 120, 121 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары сынык сызык белән көньякка таба 150 м 121 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары сынык сызык белән 50 м көньякка таба 121 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 100 м көньяк-көнчыгышка таба 121 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык белән 2,0 км көньякка таба 121 нче, 122 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Кәркәүч – Сасмак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,8 км «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгында-

гы 7 нче, 8 нче урман кварталларының көнбатыш чикләре буйлап Важашур, Түбән Өскебаш һәм Түбән Үрәс авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Люгдон поселогыннан 250 м төньякта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Важашур авыл җирлеге чиге Түбән Үрәс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Үрәсбаш авылын Иске Каенсар авылы белән тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,6 км көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көньякка таба, 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м үләт чокырының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 1,7 км көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м буаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 2,5 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

### Кукмара муниципаль районының «Каенсар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Каенсар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Каенсар авыл җирлеге Байлангар, Нырья, Оштырма-Юмья авыл җирлекләре белән чиктәш.

Каенсар авыл җирлеге чиге Байлангар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә, урман полосасын кисеп үтеп, Байлангар, Оштырма-Юмья һәм Каенсар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньякка таба, 1,4 км

төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман полосаларын һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Байлангар, Каенсар һәм Нырья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Каенсар авыл җирлеге чиге Оштырма-Юмья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Каенсар, Оштырма-Юмья һәм Нырья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чәчәк авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 100 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 23 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 200 м көнчыгышка таба 395 нче урман кварталының төньяк һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 700 м төньякка таба урман полосасының көнчыгыш һәм 550 м төньяк-көнчыгышка таба көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Каенсар авыл җирлеге чиге Нырья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 150 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кенә елгасына кадәр бара, 3,1 км бу елга агымы буенча аска таба әлеге елгага инеш койган җиргә кадәр, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м аның агымы буенча өскә таба бара, аннары 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-

көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, Куркино — Каенсар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Кәркәүч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кәркәүч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кәркәүч авыл җирлеге Важашур, Түбән Өскебаш, Чарлы авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Кәркәүч авыл җирлеге чиге Важашур авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Важашур, Кәркәүч авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Салтык Ерыклы авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасыннан алып, кибеп баручы инешнең чокырлы уң ярын кисеп үтеп, 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аның чокырлы сул ярын кисеп үтеп, 1,1 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, 550 м инеш агымы буенча аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, 500 м бу инеш агымы буенча аска таба аңа икенче инеш койган җиргә кадәр уза, 350 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 800 м көньякка таба чокыр төбеннән уза, алга таба 550 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Важашур, Кәркәүч һәм Түбән Өскебаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шөн авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кәркәүч авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Кәркәүч, Чарлы авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чарлы авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 52 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кәркәүч авыл җирлеге чиге Чарлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 52 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап, 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,6 км урман полосасы буйлап уза, алга таба, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм «Мамадыш — Кукмара» — Кәркәүч — Сасмак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Кәркәүч, Чарлы һәм Түбән Өскебаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәркәүч авылыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кәркәүч авыл җирлеге чиге Түбән Өскебаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 51 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 200 м инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лубян участок урманчылыгындагы 119 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, алга таба көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 119 нчы, 118 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, аннары көньякка таба 50 м 118 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 300 м 118 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м 118 нче, 117 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 350 м көнбатышка таба 117 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Күкшел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Күкшел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Күкшел авыл җирлеге Зур Сәрдек, Мәмәшир, Туембаш авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Күкшел авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Күкшел, Зур Сәрдек авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Күкшел авылыннан 1,5 км көнбатышта Бөр елгасында урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Күкшел, Мәмәшир авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Мәчкәрә авылыннан 250 м төньякта Бөр елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр, шулай ук Күкшел, Мәмәшир авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Мәмәшир авылыннан 700 м көньякта Бөр елгасында урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып Күкшел, Туембаш авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чаллы авылыннан 2,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күкшел авыл җирлеге чиге Мәмәшир авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 2,4 км Бөр елгасы агымы буенча аска таба 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күкшел авыл җирлеге чиге Туембаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,3 км көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык белән 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык белән 500 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 38 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба көнбатышка 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 38 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап сынык сызык белән 800 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык белән 250 м төньякка таба, сынык сызык белән 900 м төньяк-көнбатышка таба, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба Күкшел, Туембаш һәм Зур Сәрдек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Туембаш авылыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күкшел авыл җирлеге чиге Зур Сәрдек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне, Аш-Буҗи — Мәмәшир автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м карьерның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 4,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы<br>турында» Татарстан Республикасы Законына<br>12 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Лельвиж авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Лельвиж авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Лельвиж авыл җирлеге Сәрдекбаш, Югары Чура, Янил авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы белән чиктәш.

Лельвиж авыл җирлеге чиге Балтач муниципаль районы белән чиктәш җирдә Лельвиж, Югары Чура авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Поршур авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап Лельвиж, Сәрдекбаш авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тырыш авылыннан 900 м көньяк-көнбатышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Лельвиж авыл җирлеге чиге Сәрдекбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 9 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 12 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 12 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Сәрдекбаш – Лельвиж – Югары Чура автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Лельвиж, Сәрдекбаш һәм Янил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лельвиж авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Лельвиж авыл җирлеге чиге Янил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,2 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Лельвиж, Янил һәм Югары Чура авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лельвиж авылыннан 900 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Лельвиж авыл җирлеге чиге Югары Чура авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба сынык сызык белән 650 м көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сәрдекбаш – Лельвиж – Югары Чура автомобиль юлына кадәр бара, аннары 1,0 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, алга таба сынык сызык белән 400 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 300 м көньяк-көнбатышка таба

«Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль<br>берәмлекләрнең территорияләре чикләрен<br>билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>13 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Лубян авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Лубян авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Лубян авыл җирлеге Чарлы авыл җирлеге, Мамадыш муниципаль районы, Киров өлкәсе һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Лубян авыл җирлеге чиге Чарлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Лубян, Чарлы авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лубян авылыннан 2,6 км көнбатышта Нократ елгасының уң ярында урнашкан 54 нче тоташу ноктасыннан алып 3,5 км төньяк-көнбатышка таба Нократ елгасының уң яры буйлап Лубян, Чарлы авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Татар Толлысы авылыннан 900 м көнчыгышта Нократ елгасының уң ярында урнашкан 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Лубян авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 53 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Лубян авыл җирлеге, Мамадыш муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Лубян авылыннан

1,5 км көньяк-көнчыгышта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 55 нче (15 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Лубян авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 55 нче (15 нче) тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>14 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мәмәшир авыл җирлеге Күкшел авыл җирлеге һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Мәмәшир авыл җирлеге чиге Күкшел авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күкшел, Мәмәшир авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Мәчкәрә авылыннан 250 м төньякта Бөр елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып 2,4 км Бөр елгасы агымы буенча аска таба Күкшел, Мәмәшир авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Мәмәшир авылыннан 700 м көньякта Бөр елгасында урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мәмәшир авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мәмәшир авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Мәмәшир авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Мәмәшир авылыннан 6,2 км төньяк-көнчыгышта Нократ елгасы кушылдыгының сул ярында урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Манзарас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Манзарас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Манзарас авыл җирлеге «Кукмара шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Березняк, Зур Кукмара, Пүчинкә-Кучук, Пычак, Урта Кумор авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Манзарас авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Манзарас авыл җирлеге, «Кукмара шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Кәчимир авылыннан 500 м төньяк-көнбатышта 38 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Манзарас, Пычак авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Арпаяз авылыннан 450 м төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Манзарас авыл җирлеге чиге Пычак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 350 м көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м күмәк бакчаларның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң сынык сызык белән 750 м көньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, «Мамадыш – Кукмара» – Арпаяз автомобиль юлы-

на һәм Өлге, Әсән-Елга авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны ике тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 900 м көньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Манзарас, Пычак һәм Пүчинкә-Кучук авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әсән-Елга авылыннан 1,5 км көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Манзарас авыл җирлеге чиге Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км төньяк-көнбатышка, сынык сызык белән 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м торф чыгару урыны буйлап, Кенә елгасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Өлге – Нырты совхозы поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Манзарас, Пүчинкә-Кучук һәм Березняк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камышлы авылыннан 400 м көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Манзарас авыл җирлеге чиге Березняк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Манзарас, Березняк һәм Урта Кумор авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камышлы авылыннан 750 м төньякта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып сынык сызык белән 250 м көньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 393 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык белән 500 м 393 нче урман кварталының аерымланган участогы буйлап уза, 100 м көнчыгышка таба 393 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап, сынык сызык белән 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 393 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап бара, 250 м күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап уза, аннары 50 м күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Оштырма елгасына кадәр бара, 850 м шушы елга агымы буенча аска таба уза, аннары, чокырны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м күмәк бакчалар буйлап, Өлге – Иске Юмья автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп,

350 м күмәк бакчаларның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Манзарас авыл җирлеге чиге Урта Кумор авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 393 нче урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 400 м 197 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, 250 м 197 нче урман кварталы буйлап бара, 100 м 29 нчы урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 550 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 50 м төньякка таба урман массивының көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман массивы буйлап бара, шуннан соң, чокырны кисеп үтеп, сынык сызык белән 2,2 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Манзарас, Урта Кумор һәм Зур Кукмара авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Кукмара авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Манзарас авыл җирлеге чиге Зур Кукмара авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Манзарас, Зур Кукмара авыл җирлекләре һәм «Кукмара шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Зур Кукмара авылыннан 1,1 км көньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап, 350 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык белән 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 24 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Манзарас авыл җирлеге «Кукмара шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба, Кукмара – Нократ Аланы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м Кукмара – Нократ Аланы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 300 м көньяк-көнчыгышка таба Кукмара шәһәр тибындагы поселогын көнчыгыш ягыннан әйләнеп узучы автомобиль юлының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 150 м көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына

бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м Кукмара шәһәр тибындагы поселогын көнчыгыш ягыннан әйләнеп узучы автомобиль юлының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 200 м көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, Нурминкә елгасын ике тапкыр кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап уза, шуннан соң Нурминкә елгасын кисеп үтеп, 300 м көньяк-көнбатышка таба Кукмара шәһәр тибындагы поселогын көнчыгыш ягыннан әйләнеп узучы автомобиль юлының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, Нурминкә елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньякка таба, 100 м көнбатышка таба Нурминкә елгасына кадәр уза, 150 м аның агымы буенча өскә таба бара, алга таба сынык сызык белән 1,4 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 550 м көнбатышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап бара, алга таба, Кукмара шәһәр тибындагы поселогын көнчыгыш ягыннан әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык белән 1,3 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м көнбатышка таба Кукмара шәһәр тибындагы поселогын көнчыгыш ягыннан әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап бара, алга таба, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м көньякка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км төньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 1,3 км төньяк-көнбатышка, Кукмара шәһәр тибындагы поселогын әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км төньяк-көнчыгышка, 200 м төньяк-көнбатышка таба уза, урман утыртмаларын кисеп үтеп, шуннан соң 50 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м урман полосасы буйлап 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
16 нчы кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Түбән Өскебаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Өскебаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге Важашур, Кәркәүч, Түбән Үрәс, Чарлы авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге чиге Түбән Үрәс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Өскебаш, Түбән Үрәс һәм Важашур авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Люгдон поселогыннан 200 м төньякта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасыннан алып 350 м көньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 8 нче, 9 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,0 км көньяк-көнбатышка таба 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының көнбатыш, төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шуннан соң 1,3 км төньяк-көнбатышка таба 11 нче, 12 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары 900 м төньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба сынык сызык белән 1,0 км көньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Түбән Өскебаш, Түбән Үрәс авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән Үрәс авылынннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 57 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге чиге Важашур авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Өскебаш, Важашур һәм Кәркәүч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шөн авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасыннан алып сынык сызык белән 2,3 км көньяк-көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лубян участок урманчылыгындагы 117, 120, 121 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары сынык сызык белән көньякка таба 150 м 121 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары сынык сызык белән 50 м көньякка таба 121 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнчыгышка 121 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Кәркәүч – Сасмак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык белән 2,0 км көньякка таба 121 нче, 122 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, 1,8 км «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 7 нче, 8 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге чиге Кәркәүч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Өскебаш, Кәркәүч һәм Чарлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәркәүч авылыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 200 м инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лубян участок урманчылыгындагы 119 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 119 нчы, 118 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, аннары көньякка таба 50 м 118 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 300 м 118 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м 118 нче, 117 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, ан-

нары 350 м көнбатышка таба 117 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге чиге Чарлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 51 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лубян участок урманчылыгындагы 119 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык белән 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м көньякка таба 119 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 119 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 450 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 450 м уза, аннары, «Мамадыш – Кукмара» – Кәркәүч – Сасмак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 700 м көньякка таба, 1,0 км 17 нче, 18 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м һәм 100 м көнчыгышка таба бара, аннары 1,7 км 18 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, алга таба 200 м көньякка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Өскебаш, Чарлы авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Искебаш авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап 57 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Түбән Үрәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Үрәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Үрәс авыл җирлеге Важашур, Түбән Өскебаш, Пүчинкә-Кучук, Өркеш авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Үрәс авыл җирлеге чиге Өркеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Үрәс, Өркеш һәм Пүчинкә-Кучук авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәсән поселогыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып сынык сызык белән 2,4 км көньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 310, 311, 312 нче урман кварталларының көнбатыш, көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 2,5 км 313 нче, 314 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 400 м көньяк-көнбатышка таба 314 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Түбән Үрәс, Өркеш авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Өркеш авылыннан 1,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Үрәс авыл җирлеге чиге Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Үрәс, Пүчинкә-Кучук һәм Важашур авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Октябрь авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м ур-

ман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 307 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, казылмаларны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык белән 1,9 км 307, 309, 308 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,1 км көньякка таба 308 нче, 310 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Үрәс авыл җирлеге чиге Важашур авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып Үрәсбаш авылын Иске Каенсар авылы белән тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,6 км көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көньякка таба, 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м үләт чокырының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 1,7 км -көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, буаны кисеп үтеп, 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза 100 м, алга таба 2,5 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Үрәс, Важашур һәм Түбән Өскебаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Люгдон поселогыннан 200 м төньякта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Үрәс авыл җирлеге чиге Түбән Өскебаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 49 нчы тоташу ноктасыннан алып 350 м көньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 8 нче, 9 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 2,0 км көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының көнбатыш, төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,3 км 11 нче, 12 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 900 м төньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба сынык сызык белән 1,0 км көньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Түбән Үрәс, Түбән Өскебаш авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән

Үрәс авылынннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 57 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Үрәс авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 57 нче тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында» Татарстан Республикасы Законына
18 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Нырты авыл җирлеге чиге Өркеш, Ятмас-Дусай авыл җирлекләре, Мамадыш, Саба һәм Теләче муниципаль районнары белән чиктәш.

Нырты авыл җирлеге чиге Ятмас-Дусай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырты, Ятмас-Дусай һәм Өркеш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ятмас-Дусай авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 60 нчы тоташу ноктасыннан алып 200 м көньяк-көнбатышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 369 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 250 м төньяккөнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге һәм 100 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, профильле автомобиль юлын һәм Өлге – «Нырты» совхозы поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м көнбатышка таба сынык сызык белән авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 402 нче, 403 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнбатышка

таба, көньяк чиге буйлап сынык сызык белән 1,5 км көньяк-көнбатышка таба, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Өлге – «Нырты» совхозы поселогы» – Беренче Май поселогы автомобиль юлына кадәр бара, алга таба әлеге автомобиль юлы буйлап 700 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 650 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне ике тапкыр кисеп үтеп, 200 м агач-куак массивы буйлап, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, 416 нчы урман кварталының аерымланган участокларын кисеп үтеп, 550 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м 416 нчы урман кварталының аерымланган участогының төньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м 416 нчы урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, сынык сызык белән 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 550 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Нырты, Ятмас-Дусай авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ямбулат-Пустыш авылыннан 1,5 км төньякта урнашкан 61 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нырты авыл җирлеге чиге Өркеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырты, Өркеш авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Чәбия авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып 800 м Баш-Арбаш елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр уза, 2,6 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң, ишелмәләрне һәм чокырны кисеп үтеп, 600 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 5,6 км төньяк-көнбатышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 368, 367, 366 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 60 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Нырты авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап Нырты авыл җирлеге, Мамадыш һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Нырты совхозы поселогыннан 4,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 63 нче (52 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Нырты авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 63 нче (52 нче) тоташу ноктасыннан алып

Кукмара муниципаль районы чиге буйлап Нырты авыл җирлеге, Теләче һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Нырты совхозы поселогыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 62 нче (51а) тоташу ноктасына кадәр уза.

Нырты авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә 62 нче (51а) тоташу ноктасыннан алып, Кукмара муниципаль районы чиге буйлап 61 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>19 нчы кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Нырья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Нырья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Нырья авыл җирлеге Байлангар, Каенсар, Олыяз, Оштырма-Юмья, Ядегәр, Янил авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы белән чиктәш.

Нырья авыл җирлеге чиге Ядегәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырья, Ядегәр һәм Янил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сабанчы авылыннан 1,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км көнбатышка таба, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба бара, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара,

аның чокырлы сул ярын кисеп үтә, 500 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, алга таба 550 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Нырья, Ядегәр авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Күзмис авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нырья авыл җирлеге чиге Янил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырья, Янил һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Биер поселогыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып, канауны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м төньяк-көнбатышка таба уза, 50 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, урман утыртмаларын һәм канауны кисеп үтеп, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кенә елгасына кадәр, 1,1 км әлеге елга агымы буенча өскә таба уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 650 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нырья авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырья, Олыяз һәм Байлангар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нормабаш авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып сынык сызык белән 1,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 350 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Кукмара – Шәмәрдән» – Нырья – Иштуган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң сынык сызык белән 450 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң сынык сызык белән 450 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 200 м төньяк-көнбатышка чокыр төбе буенча 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нырья авыл җирлеге чиге Байлангар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Байлангар, Нырья һәм Каенсар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м чокыр төбе буйлап уза, аннары, чокырны, кибеп баручы инешнең чокырлы ярларын һәм инешнең үзен кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Нырья авыл җирлеге чиге Каенсар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырья, Каенсар һәм Оштырма-Юмья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чәчәк авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 150 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кенә елгасына кадәр бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,1 км шушы елга агымы буенча аска таба әлеге елгага инеш койган җиргә кадәр, 50 м аның агымы буенча өскә таба бара, аннары 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, Куркино – Каенсар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нырья авыл җирлеге чиге Оштырма-Юмья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нырья, Оштырма-Юмья авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кызыл Чәчәк авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 201 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Урман хуҗалыгы – Иштуган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 201 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 200 м 201 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 750 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, анна-

ры 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 200 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Нырья авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олыяз авыл җирлеге Байлангар, Зур Сәрдек, Нырья, Сәрдекбаш һәм Янил авыл җирлекләре белән чиктәш.

Олыяз авыл җирлеге чиге Сәрдекбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олыяз, Сәрдекбаш һәм Янил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Олыяз, Сәрдекбаш һәм Зур Сәрдек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олыяз авыл җирлеге чиге Зур Сәрдек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олыяз, Зур Сәрдек һәм Байлангар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Йорт авылыннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 64 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, 1,1 км инеш агымы буенча аска таба Норма елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча аска таба 1,8 км буага кадәр бара, шуннан соң 750 м төньякка таба буа буйлап плотинага кадәр бара, ан-

нары 100 м көнчыгышка таба плотинаның көньяк чиге буйлап бара, 1,4 км Норма елгасы агымы буенча аска таба Зур Сәрдек авылын әйләнеп узучы автомобиль юлына кадәр дәвам итә, алга таба 650 м төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап Бөр елгасына кадәр бара, 2,3 км бу елга агымы буенча өскә таба уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба чокырлы сул ярның төньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 350 м аның агымы буенча өскә таба бара, алга таба 800 м төньяк-көнбатышка таба чокырның көньяк кырые буйлап, чокырны кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап уза, аннары 1,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олыяз авыл җирлеге чиге Байлангар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олыяз, Байлангар һәм Нырья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нормабаш авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып, Кукмара – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман утыртмаларын кисеп үтеп, 2,8 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 64 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олыяз авыл җирлеге чиге Нырья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып сынык сызык белән 1,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 350 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Кукмара – Шәмәрдән» – Нырья – Иштуган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары сынык сызык белән 450 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 200 м төньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буенча Олыяз, Нырья

һәм Янил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Биер поселогыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олыяз авыл җирлеге чиге Янил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба икенче кибеп баручы инеш белән кушылган җиргә кадәр уза, 200 м бу инеш агымы буенча аска таба бара, аннары, инешнең чокырлы уң ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м төньяк-көнчыгышка таба, Кукмара – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м төньякка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 850 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Бөр елгасына койганга кадәр уза, әлеге елганы канау авызына кадәр кисеп үтә, аннары 450 м төньяк-көнбатышка таба канау буйлап, 250 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 100 м төньяк-көнбатышка таба торф җирләре буйлап, чокырны һәм урман утыртмаларын кисеп үтеп, сынык сызык белән 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 15 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Оштырма-Юмья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Оштырма-Юмья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге Байлангар, Березняк, Каенсар, Нырья, Урта Кумор авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы белән чиктәш.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге чиге Байлангар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Оштырма-Юмья, Байлангар һәм Урта Кумор авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Юмья авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык белән 1,8 км урман полосасының көньяк чиге буйлап Оштырма-Юмья, Байлангар һәм Каенсар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге чиге Урта Кумор авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 25 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 350 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 25 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 25 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-

көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап сынык сызык белән 250 м көньякка таба, чокырны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 50 м 25 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м 392 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба, чокырларны берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык белән 1,2 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 198 нче урман кварталының көнбатыш, көньяк-көнбатыш чикләре буйлап Оштырма-Юмья, Урта Кумор һәм Березняк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Салкын Чишмә авылыннан 1,2 км көньякта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге чиге Березняк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Оштырма-Юмья, Березняк авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сәрдәүч авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба буага кадәр уза, аннары 250 м төньяк-көнчыгышка таба буа буйлап бара, аннары 600 м инеш агымы буенча аска таба уза, шуннан соң 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, урман полосасын кисеп үтеп, 100 м уза, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырларны һәм урман полосасын берничә тапкыр кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман полосасын һәм чокырны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м сынык сызык белән авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 3,1 км инеш агымы буенча аска таба бара, аннары, юл буе урман полосаларын һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м көнчыгышка таба, Өлге – Иске Юмья автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, инешне һәм Оштырма елгасын кисеп үтеп, 700 төньяк-көнчыгышка таба 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып Кук-

мара муниципаль районы чиге буйлап Оштырма-Юмья, Нырья авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кызыл Чәчәк авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге чиге Нырья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 201 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Урман хуҗалыгы – Иштуган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м 201 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 200 м 201 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 750 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 200 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Оштырма-Юмья, Нырья һәм Каенсар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чәчәк авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге чиге Каенсар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 100 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 23 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 395 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 200 м көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 700 м төньякка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 22 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге Березняк, Важашур, Манзарас, Түбән Үрәс, Пычак, Өркеш һәм Ятмас-Дусай авыл җирлекләре белән чиктәш.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Манзарас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Пүчинкә-Кучук, Манзарас һәм Пычак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әсән-Елга авылыннан 1,5 км көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык белән 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м торф чыгару урыны буйлап, Кенә елгасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Өлге – Нырты совхозы поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш чиге буйлап Манзарас, Пүчинкә-Кучук һәм Березняк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камышлы авылыннан 400 м көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Пычак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырларны кисеп үтеп, 3,4 км көньяк-көнчыгышка таба, Пүчинкә-Кучук, Пычак һәм Важашур авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Каенсар авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Важашур авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Пүчинкә-Кучук, Важашур һәм Түбән Үрәс авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Октябрь авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Кәркәүч – Сасмак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Түбән Үрәс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп 250 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 307 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, казылмаларны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык белән 1,9 км 307, 309, 308 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,1 км көньякка таба 308 нче, 310 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Пүчинкә-Кучук, Түбән Үрәс һәм Өркеш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәсән поселогыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Өркеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, Өлге – Ныртты совхозы поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 34 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 34 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Пүчинкә-Кучук, Өркеш һәм Ятмас-Дусай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәсән поселогыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Ятмас-Дусай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м төньякка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 306 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык белән 306 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км төньяк-көнбатышка таба һәм сынык сызык белән төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, буаны кисеп үтеп, 850 м 282 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м 283 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 4,4 км 282, 281, 260, 243 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м 243 нче, 242 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Пүчинкә-Кучук, Ятмас-Дусай һәм Березняк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тәмле Чишмә поселогыннан 600 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге чиге Березняк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып, чокырны ике тапкыр кисеп үтеп, 2,5 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м чокыр буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба урман массивы буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба һәм 100 м көньякка таба бара, 850 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык белән 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба сынык сызык белән 31 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, алга таба 100 м чокыр буенча төньяк-көнбатышка таба, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча, чокырны кисеп үтеп, 850 м 31 нче урман кварталының аерымланган участогы буенча, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары сынык сызык белән көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, чокырны һәм инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап, 300 м 33 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк чиге буйлап уза, 550 м 31 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 31 нче урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Пычак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Пычак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Пычак авыл җирлеге Важашур, Манзарас, Пүчинкә-Кучук авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Пычак авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Пычак, Манзарас авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Арпаяз авылыннан 450 м төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Пычак, Важашур авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Югары Шөн авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пычак авыл җирлеге чиге Важашур авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Пычак, Важашур һәм Пүчинкә-Кучук авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Каенсар авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-

көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пычак авыл җирлеге чиге Пүчинкә-Кучук авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Пычак, Манзарас һәм Пүчинкә-Кучук авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әсән-Елга авылыннан 1,5 км көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырларны кисеп үтеп, 3,4 км көньяк-көнчыгышка таба 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пычак авыл җирлеге чиге Манзарас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 350 м көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м күмәк бакчаларның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба сынык сызык белән 750 м көньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, «Мамадыш – Кукмара» – Арпаяз автомобиль юлына һәм Өлге һәм Әсән-Елга авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны ике тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 900 м көньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 24 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының «Сәрдекбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Сәрдекбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сәрдекбаш авыл җирлеге Зур Сәрдек, Лельвиж, Олыяз, Янил авыл җирлекләре, Балтач муниципаль районы һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Сәрдекбаш авыл җирлеге чиге Балтач муниципаль районы белән чиктәш җирдә Сәрдекбаш, Лельвиж авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тырыш авылыннан 900 м көньяк-көнбатышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап Сәрдекбаш авыл җирлеге, Балтач муниципаль районы һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Югары Китек поселогыннан 1,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (14 нче) тоташу ноктасына кадәруза.

Сәрдекбаш авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 1 нче (14 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Сәрдекбаш, Зур Сәрдек авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Каенлык авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сәрдекбаш авыл җирлеге чиге Зур Сәрдек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сәрдекбаш, Зур Сәрдек һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Кукмара – Шәмәрдән» – Янсыбы – Зур Сәрдек – Тырыш автомо-

биль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Барбыш елгасына кадәр уза, 650 м бу елга агымы буенча өскә таба бара, алга таба 50 м төньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, чокырны һәм урман массивын кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м 16 нчы урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 16 нчы урман кварталының аерымланган участогы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 700 м төньяк-көнчыгышка урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 11 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сәрдекбаш авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сәрдекбаш, Олыяз һәм Янил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сәрдекбаш авыл җирлеге чиге Янил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сәрдекбаш, Янил һәм Лельвиж авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лельвиж авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Сәрдекбаш авыл җирлеге чиге Лельвиж авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 9 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 12 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 12 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м урман полосасының

төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Сәрдекбаш – Лельвиж – Югары Чура автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
25 нче кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Югары Чура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Югары Чура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Югары Чура авыл җирлеге Лельвиж, Ядегәр, Янил авыл җирлекләре, Балтач һәм Саба муниципаль районнары белән чиктәш.

Югары Чура авыл җирлеге чиге Балтач муниципаль районы белән чиктәш җирдә Югары Чура авыл җирлеге, Балтач һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 33 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 9 нчы (51 нче) тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап Югары Чура, Лельвиж авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Поршур авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Чура авыл җирлеге чиге Лельвиж авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Югары Чура, Лельвиж һәм Янил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лельвиж авылыннан

900 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба сынык сызык белән 650 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сәрдекбаш – Лельвиж – Югары Чура автомобиль юлына кадәр бара, аннары 1,0 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң сынык сызык белән 400 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 300 м көньяк-көнбатышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Чура авыл җирлеге чиге Янил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып 300 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м урман полосасы буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 400 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м чокыр буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м ишелмәләр буйлап, Бөр елгасын кисеп үтеп, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,9 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, «Балтач – Шәмәрдән» – Вахитов – Янил автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Югары Чура, Янил һәм Ядегәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көшкәтбаш авылыннан 1,2 км көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Чура авыл җирлеге чиге Ядегәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм Иныш елгасын кисеп үтеп, 250 м көнбатышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба, Югары Чура – Көшкәтбаш – Ядегәр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м урман полосасы буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 850 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 850 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 2,5 км инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң 150 м көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 500 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 150 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык белән 1,1 км 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң сынык сызык белән 1,4 км көньяк-көнбатышка таба 66 нчы, 72 нче урман кварталларының көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба 72 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Югары Чура, Ядегәр авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Шәмәрдән авылыннан 3,4 км көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Чура авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Кукмара муниципаль районы чиге буйлап 9 нчы (51 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы<br>турында» Татарстан Республикасы Законына<br>26 нчы кушымта

## Кукмара муниципаль районының «Урта Кумор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Урта Кумор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урта Кумор авыл җирлеге Байлангар, Березняк, Зур Кукмара, Манзарас һәм Оштырма-Юмья авыл җирлекләре белән чиктәш.

Урта Кумор авыл җирлеге чиге Байлангар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Кумор, Байлангар һәм Зур Кукмара авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Кумор авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып 850 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, урман полосасын кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м көньякка таба чокыр төбе буйлап, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнбатышка таба уза, алга таба 150 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасына кадәр уза, шуннан соң 250 м көнбатышка таба әлеге урман полосасының көньяк чиге буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, сынык сызык белән 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап Урта Кумор, Байлангар һәм Оштырма-Юмья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Юмья авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урта Кумор авыл җирлеге чиге Зур Кукмара авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Кумор, Зур Кукмара һәм Манзарас авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Кукмара авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып 350 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 24 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 350 м бу инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 28 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 100 м 24 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнбатышка таба, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Кумор авыл җирлеге чиге Манзарас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Кумор, Манзарас һәм Березняк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камышлы авылыннан 750 м төньякта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м

